**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___26.10.2022__ Казан шәһәре № _484_

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу тәртибе турында

2004 елның 27 июленнән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 маддәсендәге 1 өлеше 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә

**боерам:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма идарәсендә катнашуга рөхсәт алуның беркетелә торган тәртибен расларга (алга таба – Тәртип).

2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча сектор мөдиренә:

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Коррупциягә каршы сәясәт» мәгълүмат стендында Тәртипне урнаштырырга;

әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтындагы Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының рәсми порталында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

2019 елның 19 мартыннан «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкиле тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә аерым башкарма орган сыйфатында катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында» 82 нче номерлы боерык;

2019 елның 29 апреленнән «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкиле тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә аерым башкарма орган сыйфатында катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 140 нче номерлы боерык.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр В.А. Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2022 елның 26 октябреннән
484 номерлы
боерыгы белән расланды.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык) түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип яллаучы вәкиле булып Татарстан Республикасы спорт министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) торган (алга таба – министр) гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип гражданлык хезмәткәрләренең сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән Министрлыкның башлангыч һөнәри оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яки иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек ияләре ширкәтенең башка гомуми җыелышында, катнашуы очракларына кагылмый.

3. Гражданлык хезмәткәренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

4. Коммерциячел булмаган оешма белән идарәдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу гражданлык хезмәткәрләренә әлеге Тәртипкә 1 нче номерлы кушымта нигезендә язма рәвештә гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Гражданлык хезмәткәре Министрлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы затына (алга таба – җаваплы зат) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнаша башлаганчы гариза тапшыра.

6. Җаваплы затка гариза биргәнче, гражданлык хезмәткәре шәхсән үзе Министрлыкның гражданлык хезмәте уза торган структур бүлекчәсе җитәкчесенә танышу һәм вазыйфаи бурычларын үтәгәндә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итү очрагында мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында аның фикерен алу өчен гариза җибәрә.

7. Җаваплы зат кергән көнне әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча гаризаны Журналда терки.

Гаризаның күчермәсе тамга белән гаризаларны теркәү журналында аның имзасы куелганнан соң гражданлык хезмәткәренә бирелә яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрелә.

8. Теркәлгән көннән биш эш көне эчендә Җаваплы зат гаризаны карауны гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны карау барышында Җаваплы зат гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу функцияләрен билгеләүче язма аңлатмалар һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә гражданлык хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә бушлай катнашырга рөхсәт бирү яки рөхсәт итүдән баш тарту тәкъдиме булырга тиеш.

9. Җаваплы зат, бәяләмә һәм башка материалларны теркәп (булган очракта), гаризаны гражданлык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен министрга карауга тапшыра.

Министр Җаваплы заттан гариза алган көннән алып ике эш көне эчендә карар кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюция кую юлы белән рәсмиләштерелә.

10. Җаваплы зат карар кабул ителгәннән соң ике эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча сектор мөһере белән расланган министр резолюциясе куелган гаризаның күчермәсен тапшыра. Гаризаның министр резолюциясе куелган төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә куела.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу Тәртибенә 1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы
Спорт министрына
__________________
__________________________________
(Ф.И.Аи., вазыйфасы)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу турында
Гариза

2004 елның 27 июленнән «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 маддәсендәге 1 өлеше 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә миңа коммерциячел булмаган оешма ___________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(оештыру-хокукый формасы, тулы атамасы, ИНН, адрес, коммерциячел булмаган оешманың эшчәнлек төрләре, коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу формасы (мәсәлән – аерма башкарма орган буларак яки идарәнең коллегиаль органы составына керү)
белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итүне сорыйм.

Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу хезмәттән буш вакытта башкарылачак һәм мәнфәгатьләр конфликты яки вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китермәячәк.

| ______________ | ______________ | ______________ |
|---|---|---|
| (дата) | (гражданлык хезмәткәре имзасы) | (фамилия, инициаллар) |

Таныштым __________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәткәренең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе фикере)

| | | |
|---|---|---|
| (дата) | (турыдан-туры җитәкче имзасы) | (фамилия, инициаллар) |

Гаризаны теркәү турында билге:

| | | |
|---|---|---|
| (дата, номер) | (гаризаны теркәгән зат имзасы) | (вазыйфасы, фамилия, инициаллар) |

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу Тәртибенә 2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алу турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Теркәү датасы | Гариза бирүче затның вазыйфасы, Ф.И.А.и. | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы затның Ф.И.А.и. | Җаваплы затның имзасы | Кабул ителгән карар турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |